# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Конституциясенең**
**65 һәм 76 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Конституциясенә (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9-10; 1994, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 2-3, № 12; 1996, № 11; 1999, № 6, № 8 (I өлеш); 2000, № 3 (3), № 6 (5), № 12 (10) I өлеш; 2001, № 7-8; 2002, № 3-4; 2003, № 9 (I өлеш); 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2010, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 65 статьяның өченче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 76 статьяда:

а) беренче өлештә "Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе" сүзләреннән соң ", Татарстан Республикасы Прокуроры" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

"2. Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү буенча закон чыгару инициативасына Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санының кимендә өчтән бере, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Конституция суды ия.";

в) икенче өлешне өченче өлеш дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 22 ноябре
№ 79-ТРЗ